**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ПОДГОРНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXVI СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Подгорный бистәсе 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Подгорный авыл җирлеге» Башкарма комитеты турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 3 июлендә кабул ителгән Подгорный авыл җирлеге Советының XXV сессиясенең №2 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Подгорный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

**Подгорный авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Подгорный авыл җирлеге» Башкарма комитеты турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 3 июлендә кабул ителгән Подгорный авыл җирлеге Советының XXV сессиясенең 2нче карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4 бүлектә:

- *2 пунктның 5 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:*

«- Подгорный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр, товарлар сатып алуны гамәлгә ашырга»;»;

1.2. 5 бүлектә:

- *13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:*

«13) «Подгорный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эшләү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Подгорный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы** **М.Ф. Мөбәрәкшин**